## Ш.Рәкыйпов очеркларының композициясе
## Аннотация

Совет чорында очерк газета - журналларның даими жанрына әйләнде.

Ә чит ил әдәбияты теориясендә алар “эссе”, “эссей”,”репортаж “, “этюд” дип тә аталалар. Ә эссе белән очерк  арасындагы ныклы аермалар турында әле һаман да төпле нәтиҗәләр күренми. Татар әдәбиятында А.Ә.Әхмәдуллин төзегән сүзлектә эссега түбәндәге мәгънә бирелә: ”(латинча “үлчәп карау” дигән мәгънәдә) инглиз һәм француз теленә очерк, мәкалә мәгънәсендәрәк тәрҗемә ителә. Ә гомумән, эссе – ул тәнкыйть жанры, язучы үзе сайлап алган нинди дә булса проблеманы ирекле хәлдә үзе тасвирлый.  Эссе свторы әдәби, эстетик, фәлсәфи һәм башка төр проблемаларны анализлый. Хәзерге әдәбият белемендә эссе – ул фәлсәфи-теоретик уйланулар, эзләнүләр белән сугарылган очерк яки мәкалә.

Очерк – үз күзе белән күргәнне тасвирлап, сөйләп чыгуга корылган эпик жанр. Очерк кешеләрнең аерым сыйфатларын, табигать күренешләрен сурәтләү белән генә чикләнми, персонажларның эш-хәрәкәтләрен, уй-фигыльләрен, үзара мөнәсәбәтләрен дә сурәтли. Очеркның документаль(яки публицистик) һәм художестволы төрләре бар. Беренче төре чынбарлыктагы вакыйгаларны ничек бар, шулай тасвирлый. Мондый очракта очерк иҗат итүче гомумиләштерелгән фикер әйтү өчен публицистик юл сайлый. Художестволы очерк кешеләрнең яшәеш шартлары эченнән тотрыклы мөнәсәбәтләрне эзли. Шуңа күрә ул кеше характерын типик итеп тасвирларга омтыла. Очерк сюжетын төзегән вакыйгалар юлдагы очрашулардан, очраклы сөйләшүләрдән гыйбарәт. Мөстәкыйльлекләрен саклаган хәлдә очеркның бу ике төре күп гасырлар буена янәшә яшиләр һәм бер-берсен баеталар.